КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 ноябрь г.Казань № 1018

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карары белән расланган Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль

берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 август, 697 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба шул ук эзлеклелектә – чаралар, башка бюджетара трансфертлар) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.»;

9 нчы пунктның бишенче абзацында «күчемсез милек» сүзләре алдына «, чагыштырма базар бәяләре (базарны анализлау) ысулы белән билгеләнә торган» сүзләрен өстәргә;»;

16 нчы пунктның беренче абзацында «Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсе булып» сүзләреннән соң «базар кыйммәтен бәйсез бәяләү үткәрү,» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин